Тайга кызы

Яңа Тинчәледә тайга кызының аучылык шөгыле хобби булып кына калган инде хәзер. Чөнки бездә киек җәнлекләр белән тулган урман юк. Куян артыннан куса гына инде. Анысы булгалый, ләкин беркайчан да максаты аларны атып үтерү түгел. Мылтыкны да кыяфәте килсен һәм кыргый этләрдән сакланыр өчен генә ала хәзер Сәфинә Алиуллова.

6 БИТ

«Икеле капчыклары» түгел!

«Күптән түгел генә республикабызда «WorldSkills» эшче һөнәрләр чемпионаты үтте. Анда катнашучылар арасында бер генә дә «2»легә укучы юк. Зиһенле, актив, үз максатларына ирешә торган балалар. Ләкин аларга һәрвакыт кимсетеп карыйлар. Һөнәри уку йортларына вуз күләгәсеннән чыгарга вакыт», – ди Лариса Сулима.

5 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 14.02.2017 | №15 (5777)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ЧҮПКӘ БАТМАБЫЗМЫ?

Завод төзелешен халык белән хәл итәчәкләр

smitsmity.livejournal.com

«Казанда гына да ел саен 600 мең тонна каты көнкүреш калдыклары җыела. Бу сан ел саен арта бара. Чүп-чарның бары 7-10 проценты гына икенчел чимал буларак эшкәртелә. Калган калдыклар Казанда ике полигонда күмелә. Икенче полигон әле сентябрьдә генә эшли башлады. Әмма аның хезмәт итү вакыты бары ун елга исәпләнгән. Шуңа да 2026 елларга шәһәр халкының үз калдыкларына күмелү куркынычы бар. Нәтиҗәдә әйләнә-тирә мохит тә, һава да пычранačак. Бүген моңа охшаш хәл Чиләбе, Мәскәү өлкәләрендә, Россиянең башка субъектларында күзәтелә. Чүп-чарны термик таркату ысулы белән эшкәртү күпкә отышлырак».

Күптән түгел «Шәһри Казан» журналистлары Казанда көнкүреш калдыкларын, чүп-чарны эшкәртү, аралау, юкка чыгару белән шөгыльләнгән иң зур оешмаларның берсе – «Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән ширкәтенең эшчәнлеге белән танышып кайткан иде.

Эльвира МОЗАФФАР

Татарстанда калдыкларны күмүдән бигрәк, аларны икенчел чимал буларак куллануга басым ясыйлар. Тик ничек кенә булмасын, чүп-чарның бик азы гына эшкәртелә. «Чүплекләрдән арыну өчен, Казан янында заманча чүп-чар яндыру заводын төзергә җыеналар» дигән хәбәр дә таралды. Халыкта ул шактый шау-шу уятты. Берәүләр аны экологик яктан зыянлы дип уйласа, икенчеләр, бәлки, чынлап та тонналаган чүп-чарны эшкәртүдә нәтиҗәле алым булыр, дип өметләнә.

Гыйнвар аенда Татарстан делегациясе Мәскәүгә баргач, Бирюлево сәнгать зонасында урнашкан заманча чүп-чар яндыру заводы эшчәнлеге белән танышып кайткан иде. Делегацияне Дәүләт Советының экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе Таһир Һадиев җитәкләде.

– Мәскәү чүп-чарны эшкәртүдә заманча принциплар куллану буенча Россиядә иң алга киткән шәһәр булып санала, – ди Таһир Һадиев. – Тик ничек кенә булмасын, андагы өч завод та барлык көнкүреш калдыкларының 10 процентын гына эшкәртергә сәләтле.

→ Ахыры 3нче биттә.

vk.com

«Халык контроле»ннән Дәүләт Думасы да файдаланачак

Россия Дәүләт Думасы рәисе Вячеслав Володин эш сәфәре белән Казанга килде. Визиты барышында ул IT-паркта булып, югары технологияләр өлкәсендәге технопарк резидентлары белән танышты, дип яза «Татар-информ».

– IT-индустрия – безнең дәүләттә бүген иң өметле тармакларның берсе. Ул кызу үсештә, – дип, Вячеслав Володин IT-эшмәкәрлек вәкилләрен дәүләт белән бергә сөйләшеп, канундагы нинди җитешсезлекләр тармакның үсешенә комачаулавын билгеләргә һәм аларны чишү юлларын табарга чакырды.

Республиканың мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Роман Шәйхетдинов аңа парк, анда эшләүче кешеләр, гамәлгә ашырыла торган проектлар хакында кыскача мәгълүмат бирде. «Халык контроле» һәм «Электрон хөкүмәт» порталы белән таныштырды. «Халык контроле» программасы Вячеслав Володинда кызыксыну уятты. Бу система хакында мәгълүмат тыңлаганнан соң, ул Рөстәм Миңнеханова шуңа охшаш системаны Дәүләт Думасы өчен кулланырга кирәклеген әйтте һәм тәкъдимен җиткерде.

– Безгә дә шундый программа булдырырга кирәк. Без Татарстанда депутатлар эшчәнлегенә тәэмин итә торган программага заказ бирәчәкбез. Программа депутатларның гражданнарны кабул итүен һәм мөрәҗәгатьләрен контрольдә тотарга тиеш. Шулай ук ул Дәүләт Думасы комитетлары эшчәнлегенә бәйле булачак. Комитетларда ничә канун каралган, ничәсе каралырга тиешлеге, вакыт аралыкларына сыешу-сыешмаулары күрсәтеләчәк, – диде Дәүләт Думасы рәисе.

Моннан тыш, ул Татарстандагы Иннополис базасында экспертлар мәйданын булдыру кирәклеген әйтте.

– Әлеге мәйданчыклар экспертизалар үткәрү белән генә шөгыльләнмичә, канунарны язганда тәкъдимнәрегезне дә кертерлек булсын иде. Безгә Россиядә IT-технологияләрне үстерү өчен хокукый кыр булдырырга кирәк, – диде Дәүләт Думасы рәисе.

Вячеслав Володинга «Дәүләт заказы» системасы эшчәнлеге хакында, IT-паркта эшләнелгән «maksat» кушымтасын һәм медицина анализларын теркәү өчен файдаланыла торган яңа җайланма, «Глонасс +112», «Автодория» мәгълүмати системасы да тәкъдим ителде.

Казанга визиты кысаларында, Вячеслав Володин Иске Татар бистәсенең тарихи объектлары белән дә танышты.

Банкрот икәнсең, эшләмә

«Татфондбанк» эше буенча тикшерү дәвам итә. Күпләр өчен банкны коткаручы санатор табылуы мөһим. Бу очракта кертемнәре иминиятләштерелмәгән клиентларның да акчаларын саклап калу мөмкинлеге бар.

Билгеле булганча, күпләр, акчаларын «ТФБ Финанс» инвестиция компаниясенә күчереп, ярык тагарак алдында калды. Кертемнәре 1 миллион 400 мең сумнан артмаган кешеләр үз акчаларын махсус билгеләнгән банк-агентлар аша кайтара алды. Тик менә акчаларын «ТФБ Финанс» компаниясенә («ТФБ Финанс» «Татфондбанк»ның бүлендеге булып санала) күчергәннәрнең кертемнәре иминиятләштерелмәгән булып чыкты. Шунысы да бар, клиентларга акчаларны күчерү операциясе вакытында бу хакта кисәтмәгәннәр дә. Нәтиҗәдә, алданган клиентлар хокук саклау органнарына шикаятьләр белән мөрәҗәгать итте.

3 февраль көнне бу мәсьәлә буенча Татарстан Эчке эшләр министрлыгының Баш тикшерү идарәсе «Аеруча зур күләмдә урлашу» маддәсе буенча җинаять эше ачты. Әлеге эштә гаепле дүрт кеше ачыкланды. Бу хакта газетабызның узган саннарында хәбәр иткән идек.

Күптән түгел соңгы гаепләнүче – «Татфондбанк» идарәсе рәисе урынбасары Вадим Мерзляков та 2 апрельгә кадәр кулга алынды. Тикшерүчеләр үтенечен судта дәүләт гаепләүчесе дә хуплады.

Бу арада Россия Финанс министрлыгы һәм Үзәк банкы банкротлыкка чыккан банклар хуҗаларын үз һөнәрләреннән читләштерү турындагы законга төзәтмәләр эшли, дип хәбәр итә «Известия» газетасы. «Һөнәреннән читләштерү вакыты банкротлыкка чыккан банкның кредит һәм вклад кертүчеләрне югалту күләменә бәйле булачак», – дип хәбәр иткән Финанс министрлыгы вәкиле. Хәзерге вакытта һөнәрдән читләштерү иң күп дигәндә биш ел тәшкил итә, ә Үзәк банкның «кара исемлеге»ндә 6 меңнән артык кеше исәпләнә икән.

Физик мөмкинлекләре чикле кешеләргә, шәһәр яны тимер юлында уңайлыклар тудыру өчен, «Содружество» пассажир компаниясе ярдәм күрсәтә.

Поездларда ярдәм итәләр

Физик яктан мөмкинлекләре чикле кешеләрне компания хезмәткәрләре вагонга кадәр илтеп куя. Шулай ук тиешле урынга кадәр озата да бара.

– Тимер юлларда барлык пассажирларга да уңайлыклар тудыру кысаларында барлыкка килде бу идея. Бер кешегә генә ярдәм итсәң дә, бу – зур нәрсә. Былтыр менә инвалид арбасында хәрәкәтләнгән спорт командасын Ижаудан озатып җибәргән идек. Күзе күрмәүчеләр еш ярдәм сорый, – ди компаниянең матбугат үзәге хезмәткәре Евгения Андреева.

Әлеге ярдәм Казан – 1, Восстание – Пассажир, Әгерҗе, Ижау, Куеда, Чернушка станцияләрендә гамәлгә ашырыла. Ярдәмгә мохтаҗ кешеләр поезд китәргә ун көн алдан **cou2013@mail.ru** электрон почтасы яки **(843)294-12-00, 89376250433** телефоны аша заявка калдыра ала.

Җимерер өчен йорт салалармы?

Тормышта акылы аек кеше, гадәттә, йортны догалар укып, матур итеп гомер кичерү максаты белән сала. Ни гаҗәп, кайбер йортлар төзелеш тәмамлангач яки төзелеш барышында ук кире сүттерелә. Сәбәбе нәрсәдә соң?

– Төзелешләр өчен 2012 елда 423 рөхсәт бирелгән булса, узган ел әлеге сан 806 иде. Шуның 87се күпкатлы йортлар, 168е җәмәгать кулланышындагы биналар һәм 551е шәхси торак төзелеше өчен, – дип хәбәр итте шәһәр Башкарма комитетының шәһәр төзелеше рөхсәтләре идарәсе җитәкчесе Наил Галиев кичә «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә.

Ләкин кайбер намуссыз һәм комсыз затлар проектта расланган сызымнарны, нормативларны сакламый. Мәсәлән, бер иптәш Идел буе районының Алтан бистәсендә рөхсәт ителгән ике кат урынына биш катлы йорт күтәреп куйган. Кече Клыки бистәсенең Большая Красная урамындагы 128нче йорт адресындагы «өй» 1 мең квадрат метрга кадәр зурайган. Комиссия аны «өй түгел, ә административ бина» дип бәяләгән.

– Узган ел рөхсәтсез рәвештә проектны үзгәртеп төзелгән ун корылма суд карары нигезендә сүттерелде. Әле тагын 45 корылма сүттереләчәк, – диде Наил Галиев.

Ун корылманың дүртесен шәһәр Башкарма комитеты сүттергән, алтысын милек хуҗалары үзләре сүткән.Милек хуҗасы рөхсәтсез төзегән корылмасын сүтмәсә, суд карарын үтәмәсә, аңа штраф салына. Суд корылманы – йортны сүтә башлау көнен билгели. Әгәр милекче корылманы – йортны шушы көндә сүтәргә керешмәсә, аңа һәр көн өчен пени хисапланыла башлый.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 26 мартында кабул иткән 188нче карары нигезендә, Казан төбәк әһәмиятендәге тарихи торак пункт санала. Мэр Илсур Метшин, үзенең фикерләре белән уртаклашканда, шушы карарны телгә алып үтте.

– Без хәзер Казанның Дәрвишләр бистәсендә булсынмы, «Салават күпере» торак комплексындамы, төзелеш башлар алдыннан Мәдәният министрлыгыннан рөхсәт алырга тиеш, – диде Илсур Метшин. – Бу кирәкле карар. Казанның тарихи үзәгендә ике дистә ел дәвамында кире төзәтеп булмаслык төзелешләр үткәрелде, тарихи мираска зыян китерелде. Төзелешләр закон кысаларында алып барылырга тиеш. Технологияләр сакланылмаган төзелеш кешеләрнең иминлегенә куркыныч тудыра.

Дамир БӘДРИЕВ.

«Болай булмаска тиеш!»

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Питрәч районы – эшләү һәм яшәү өчен дә иң уңайлы районнарның берсе. Табигать тә аны кимсетмәгән, су дисәң, суы бар, туфрак та уңдырышлы. Районның иң отышлы якларының берсе – әлбәттә инде, аның Казанга якын урнашуы. Каланың азык-төлек базары иркен, нәрсә генә җитештереп сатсаң да, рәхәтләнеп табыш алырга була. Әлеге потенциал тулысынча кулланыламы соң? Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында узган Питрәч муниципаль районының 2016 елгы эш нәтиҗәләре һәм 2017 елга куелган бурычларга багышланган район советы утырышында сүз нәкъ әнә шул хакта барды. Беренче карашка, районның икътисади хәле алай начар түгел кебек. Тик һәр тармакны анализлап караганда, районның башлыча «Ак Барс холдинг» хисабына гына яшәгәнлеге күренә. Рөстәм Миңнеханов, үзенең чыгышында районның икътисади хәленә анализ ясап, утырышта катнашучыларга су астында яткан барлык ташларны «табып», кимчелекләрен ачып бирде.

prav.tatarstan.ru

АЗЫК-ТӨЛЕК БАЗАРЫ

Агросәнәгать комплексы буенча рейтингта Питрәч – 25енче урында. Кече хуҗалык формалары буенча республика күләмендә – 33нче урында. 2015 елда 20нче урында булганнар. Районда 14 гаилә фермасы бар, 2016 елда нибары дүрт мини ферма төзелгән. Республика буенча 1205 гаилә фермасы эшли, 107се төзелү стадиясендә, 3 мең эш урыны булдырылган. Ике ел эчендә 824 шәхси ярдәмчел хуҗалык мини-фермаларга субсидия алган.

– Кукмараны алсак, анда – 43, Мамадышта – 107. Сез бу мәсьәләләрдә калышасыз, димәк, эшләп бетермисез. Бу авыл җирлекләре башлыкларына да кагыла. Авыл җирлекләре белән эшчәнлекне җанландырырга кирәк. Продукция булмаса, авылның киләчәге юк. Тәүлек саен 51 тонна сөт җитештерәсез. Әтнә районын алсак, 178 тонна, район кечерәк булса да, өч тапкыр күбрәк сөт бирә. Сабада – 141 тонна, Кукмарада – 200 тонна. Сез Казан янәшәсендә генә, базарыгыз шунда. Мин Питрәчнең күп кенә районнар өчен бу мәсьәләдә үрнәк булганын, сезгә өйрәнергә килгәннәрен хәтерлим. Бу мәсьәләгә игътибар кирәк, – дип, Рөстәм Миңнеханов, башка районнар мисалында, Питрәчнең бүгенге көндә тоткан урынын күрсәтте.

«СЕЗНЕҢ ТӨП ХӘЗИНӘГЕЗ – ҖИРЛӘР»

Районның 789 гектар авыл хуҗалыгы җире сәнәгать төзелеше өчен бирелгән һәм ул тиешенчә кулланылмый.

– Авыл хуҗалыгы җирләрен башка формаларга күчерүгә, нинди дер производстволарга мин каршы түгел, әмма сездә күп кенә җирләр күчерелгән, ә файдасы юк. Алар йә авыл хуҗалыгы, йә торак төзелеше, йә сәнәгатьтә файдалану өчен эшкә җигелми. Җирне акылсыз таратырга ярамый, ул беркайчан артмаячак. Әгәр бу җир тиешенчә файдаланылмый икән, кире авыл хуҗалыгына тапшырырга кирәк. Производство булмаган өстенә акылсыз рәвештә торак төзүнең дә кирәге юк, – дип үз фикерен белдерде Президент.

Район торак йортлар төзү өчен шактый зур чыгымнар тота. Анда яшәүчеләрнең күбесе Казанга йөреп эшли.

– Бу кешеләр көн саен килеп-китеп йөрсәләр, алар керемгә салым түләмәячәк, ә сез балалар бакчалары, мәктәпләр, аларның сәламәтлеге өчен җавап бирәчәксез. Монда яшәп эшләсеннәр. Әгәр эш булмаса, торак кына төзесәгез, сез кире нәтиҗә алачаксыз, – дип, Рөстәм Миңнеханов бу мәсьәләләргә игътибарлы булырга һәм балансны сакларга кирәклеген искәртте. Аның фикеренчә, торак төзегән җирдә сәнәгать мәйданчыклары булырга тиеш.

Кызганыч, кече бизнес буенча да район бары тик 37нче урында гына. Географик яктан бик уңайлы урнашкан булса да, районда зур сәнәгать тә юк. Сәнәгать мәйданчыгында да бары тик ике генә резидент.

«БЕРКАЙДА ДА АНДЫЙ НӘРСӘ ЮК»

Рөстәм Миңнеханов үзара салымга да аерым тукталды. Питрәч буенча барлыгы 26 млн сум җыелган.

– Гражданнар җыйган 1 сумга 4 сум бирәбез, беркайда да андый нәрсә юк. Күп кенә районнар моннан яхшы файдалана. Кеше үзенең акчасын кертсә, ул аңа төзелгән юлга, зиратка һәм башкаларга икенче төрле карый. Мин шушы мәсьәләләргә игътибар сорыйм, – диде ул.

СӘЛАМӘТЛЕК БУЕНЧА – 37, МӘГАРИФ БУЕНЧА – 33НЧЕ УРЫНДА

Рөстәм Миңнеханов бу уңайдан да канәгатьсезлеген белдерде.

– Халык саны үсеше буенча күрсәткечләр ярыйсы, тик белмим, сәбәпләре нидәдер, әмма сәламәтлек саклау өлкәсендә сез 37нче позициядә. Эшкә сәләтле халыкның инфаркт миокардиннан, яман шештән һәм яңа туган балалар үлү күрсәткечләре югары. Аналар үлеменең дүрт очрагының берсе сездә, 37нче урын сезне бизәми дип уйлыйм, – дип белдерде Президент һәм республиканың сәламәтлек саклау министры Адел Вафинга район башлыгы белән тикшерү үткәрергә йөкләмә бирде.

Рөстәм Миңнеханов электрон юл белән табибка язылучылар арасында канәгатьсезлек белдерүчеләр саны югары булуын да ассызыклап узды.

Мәгариф буенча да эшләр мактанырлык түгел.

– Район 33нче урында һәм сез үзегезнең тырышлыгызда бу турыда берни әйтмәдегез, – дип, район башлыгына мөрәҗәгать итте Президент. Аннан соң районның мәгариф бүлеге җитәкчесен дә бастырды. Аның: «Икенче ел гына эшлим», – дигәненә, «Бу синең бәхетең», – дип тә әйтеп куйды. – Сезнең район мәктәпләрендә белем алган балалар мондый билгеләр белән Казанга барып бернинди дә уку йортларына керә алмаячак.

Район җитәкчелегенә карата бик күп шелтә сүзләре әйтелсә дә, утырыш бик тыныч мохиттә үтте.

– Кимчелекләрне бетерү өстендә эшләргә кирәк. Алла боерса, икенче елга килербез, нинди үзгәрешләр булуын карарбыз, – дип саубуллашты Рөстәм Миңнеханов.

Чүпкә батмабызмы?

→ Ахыры. Башы 1нче биттә.

Татарстан делегациясе шул өч заводның берсендә булган. Көн саен бирегә мең тоннадан артык көнкүреш калдыклары китерелә икән. Предприятиенең төп принцибы – чүп-чарны экологик яктан куркынычсыз итеп эшкәртү һәм шул ук вакытта энергияне дә саклык белән куллану. Чүпне махсус пар көче җайланмасы белән эшкәрткәндә, электр энергиясе эшләп чыгарыла. Шул рәвешле Мәскәүдә 48 мең хуҗалык җылылык һәм кайнар су белән тәэмин ителә. Россиядә мондый заводларны табигатьне саклау законнары кысаларында төзиләр.

– Быел Россиядә «Калдыкларны тулысынча күмеп бетерү» пилотлы проекты гамәлгә ашырыла башлады. Аның кысаларында Мәскәү өлкәсендә – дүрт, Казанда бер чүп-чар яндыру заводы төзү ниятләнелә, – диде комитет рәисе. – Бүген завод төзү өчен шәһәрдән ун чакрым ераклыкта хәзер ябылган «Самосырово» чүплеге янындагы «Восточный» полигоны тирәсендә урын билгеләнгән. Төзелеш 2021 елда төгәлләнер дип фаразлана.

Әңгәмәдәшебез әйтүенчә, завод елына 550 мең тонна калдык эшкәртергә сәләтле. Биредә каты көнкүреш калдыклары махсус казанда яндырылачак, термик таркату технологиясе кулланылачак.

– Күмелгән чүп-чар күләмен ул ун тапкырга киметергә ярдәм итәчәк. Өстәвенә, республика җитәкчелеге чүп-чарны яндырудан электр һәм җылылыкны тәэмин итә торган энергия дә алырга җыена, – дип искәртте Таһир Һадиев.

Без завод төзү уңаеннан туган каршылыклы фикерләр турында искә төшердек. Әңгәмәдәшебез күп нәрсә халыкның завод эшчәнлеге турында хәбәрдар булмавыннан дигән фикердә.

– Халыкның: «Чүп-чар эшкәртелгәндә, токсиннар бүленеп чыкмыймы, алар сәламәтлек өчен зыянлы түгелме?» – дип борчылуы аңлашыла. Бүген чүп-чарны эшкәртү өлкәсендә заманча, яңа, куркынычсыз технологияләр кулланыла, – диде ул һәм халык фикере дә аяк астына салып тапталмаячак дип искәртте: – Федераль законнар җыелмасы нигезендә бары иҗтимагый тыңлаулар, дәүләт экология экспертизасын узганнан соң гына завод төзергә рөхсәт биреләчәк. Халык чын-чынлап табигать өчен борчыла икән, һәр кеше билгеле бер көнне 15-20 минут вакытын үзе яши торган тирәлекне җыештыруга багышласын иде. Моның өчен бер чара уйлап табарга кирәк. Табигатьне саклауга халыкны никадәр күбрәк җәлеп итсәк, нәтиҗәсе дә шулкадәр күбрәк булачак. Каты көнкүреш калдыкларын аерып җыю культурасын булдыру да мөһим, чүп-чарны тиешсез урынга түгү өчен бәлки штрафларны катгыйландырырга кирәктер.

Мигрантларны кыерсытмыйлар

МИЛЛИЯТ

Татарстан Мәдәният министрлыгында «2014-2020 елларда Татарстанда дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» һәм «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2014-2016)» дәүләт программаларының узган елгы эшчәнлегенә нәтиҗәләр чыгаруга багышланган киңәйтелгән утырышында республика министрлыклары һәм ведомстволары эшләнгән эшләре турында хисап тоттылар.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисенең беренче урынбасары Данис Шакиров сүзләренә караганда, өч ел эчендә конгресс 157 чарада катнашкан. Шуларның 58е программа кысаларында 2016 елда гамәлгә ашырылган. Ел дәвамында ана телен дистанцион рәвештә өйрәтү максатыннан, татар телен өйрәнергә теләгән катнашучыларны туплауга, югары уку йортларында белем алу өчен Россия төбәкләреннән, ерак чит илләрдән талантлы татар яшьләрен җәлеп итүгә ярдәм күрсәтелгән. Татарлар яшәгән чит төбәкләрдә этно-мәдәни үзенчәлекне саклау буенча, «Пар канатлар» гаилә бәйгесе үткәрелгән.

Татарстан мәдәният министры урынбасары Гүзәл Шәрипова әйтүенчә, төрле милләтләрнең бәйрәмнәре дә халыкта зур кызыксыну уяткан. Узган ел, мәсәлән, татар халкының милли бәйрәме – Сабан туе 321 урында узды-рылган. Шул исәптән 249ы Россиянең 57 субъектында булса, 72се якын һәм ерак чит илләрдә уздырылган.

Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Клара Таҗетдинова «2014-2020 елларда Татарстанда дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» программасы кысаларында өч төрле проектны тормышка ашырулары хакында хәбәр итте. Алар арасында мигрантларга рус теле, Россия тарихы һәм законнарын өйрәтү программасы да бар.

Утырышта мигрантлар темасына кагылышлы борчылуларын Иҗтимагый совет әгъзасы Юрий Балашов та җиткерде.

– Планлаштырылган барлык эшләрнең башкарылып чыгуы яхшы анысы, – диде ул. – Әмма бүген хисап кына тыңлыйсы килми бит, бу эшләрнең нәтиҗәләрен дә беләсе иде. Барысы да шулкадәр яхшымыни? Гадәттә, тормыш каршылыклардан тора һәм шуларны җиңеп чыгу бәрабәренә алга бара. Мәсәлән, узган ел университет бер социологнең тикшеренү нәтиҗәләрен бастырып чыгарган иде. Анда, мәктәп мигрантларны кире кага, дигән фикер күтәрелгән. Гомумән алганда, халык мигрантларга начар мөнәсәбәттә түгел анысы, әмма мәктәпләрдә проблемалар бар. Менә бу очракта нәрсә эшләргә соң?

Президент департаментының милли сәясәтен тормышка ашыру буенча идарәсе җитәкчесе Данил Мостафин аңа үз җавабын бирде.

– Әлеге мәгълүматны җиткергән автор материалларының беренчел нәтиҗәләре белән генә урталашуын таныды. Анда бары тик йөз кешенең генә фикере өйрәнелгән. Бу очракта әлеге мәкалә нигезендә генә укытучыларның мигрантларга булган мөнәсәбәтенә бәя бирү дөрес булмас иде. Мәсьәлә тагын каралыр әле. Социологик тикшеренүләргә карата булган таләпләр турында сөйләсәк, бу очракта тәнкыйть урынсыз. Шуңа күрә әйдәгез, университет нәтиҗәләрне карасын, өйрәнсен, аннан соң барысы да үз урынына кайтыр. Чөнки республикада, шул исәптән миграция берләшмәләрендә дә барлык социологик тикшеренүләр мигрантларга булган мөнәсәбәт яхшы икәнлеген күрсәтә. Бу мәсьәләдә борчылырлык урын юк, – диде ул.

МӘРХӘМӘТ

Алтын балыклы «Акчарлак»

Хатын-кыз, кем генә булса да, нинди генә югары дәрәҗәләргә күтәрелсә дә, игелек-шәфкать сагында тора. Татарстан Дәүләт Советы хатын-кыз депутатларның «Мәрхәмәт-Милосердие» оешмасы узган ел азагында «Бергә булдырабыз» дигән яңа проект башлап җибәрде.

Республикабызның 18 балалар һәм үсмерләр приютына ярдәм күрсәтүгә нигезләнгән ул. Максаты – киң җәмәгатьчелек игътибарын андагы проблемаларга юнәлтеп, әти-әни назыннан мәхрүм калган балаларга күңелләрен юатырга, тормышта үз урыннарын табарга ярдәм күрсәтү. Әлеге проектның ничек тормышка ашырылуы турында Балык Бистәсе районы Югары Тегермәнлек авылында урнашкан «Акчарлак» приюты директоры Илгизәр Шакиров белән сөйләштек.

– Халык илчеләре – депутатларның безнең проблемаларга игътибарны көчәйтүе бик сөендерде. Әлеге проектка без беренче көннәрдән үк кушылдык. Бүген приютыбызда 25 бала тәрбияләнә. Болар – ятимышлары юллар чатында калган малайлар һәм кызлар. Аларның беринди гаепләре дә юк. Бөтен гаеп – әти-әниләренең җаваплылык хисе булмауда. Безнең балаларны киләчәктә өч юл көтә: беренчесе – әти-әниләре аңга килеп, дөрес яши башласалар, үз гаиләләренә кайту. Икенчесе – ятим исеме тагылып, балалар йортына озатылу. Өченчесе – яңа гаиләләргә уллыкка, кызлыкка алыну. Менә шул язмышлары хәл ителгәнче, алар бездә яшәп торалар. Без аларны авырлыклар алдында куркып калмаска, ялгышлар ясамаска, тормышта үз урыннарын табарлык һөнәргә өйрәтергә тиеш булабыз. Депутат хатын-кызларыбыз башлап җибәргән «Бергә булдырабыз» проекты да шул максатны күздә тота. Ул безнең балаларның тормышын җанландырып җибәрде.

Безнең приютта көнкүреш эшләре һәм хезмәт белән тернәкләндерү кабинетлары элек тә бар иде. Әлеге проектның «Үзем булдырам» юнәлешенә кушылып, аларны яңа эш кораллары, станоклар белән баеттык. Малайлар буш вакытларын шунда үткәрергә ярата хәзер. Кызларыбызны да уңган, булган итеп үстерәсебез килә. Аларга заманча тегү машиналары алдык. «Тылсымлы энә» түгәрәгенә йөрүчеләр хәзер үзләре теләгән киемнәрне тегеп кия ала. «Яшь балта остасы» дигән түгәрәктә дә егетләр алтын куллы булып үсәргә өйрәнәләр, бу һөнәрләрнең барысы да киләчәктә кирәк булачагын аңлыйлар. Әлеге түгәрәкләр гомерлек һөнәрләрен сайларга да ярдәм итәчәк аларга, – дип сөйләде ул.

Директор әйтүенчә, «Спортны сайлыйм» юнәлеше буенча да киң эш җәелдереп җибәрергә җыеналар «Акчарлак»та. Берьюлы берничә спорт төре мәйданчыгы төзергә уйлыйлар. Моның өчен гамәлдән сызылган биналарны сүтеп, аның урынына яңа мәйданчык ясарга ниятлиләр. Чаңгы, тимераяк, волейбол сеткасы, баскетбол боҗралары алырга планлаштыралар. Дүрт яңа велосипед җәйне көткән арада чаналар, кәшәкәләр гел кулланышта.

Проектның тагын бер юнәлеше «Кунак булмәсе» дип атала. Балалар кунаклар килүен бик ярата, ә кунаклар кучтәнәчсез йөрми. Әти-әниләре килгән көн– вакытлыча ятим калганнар өчен зур бәйрәм. Шуңа да якыннары белән бергә үткәрә торган кадерле сәгатьләр өй шартларында узсын дип тырышалар «Акчарлак»та. Хәзер балалар якыннарын, кадерле кешеләрен матур итеп төзекләндерелгән, яңа йомшак кәнәфи-диваннар куелган бүлмәдә каршылый. Анда нәкъ өйдәге кебек – гөлләр үсә, аквариумда алтын балыклар йөзә. Балалар биредә алтын балыкларга үзләренең эч серләрен дә сөйлиләр. Ә аларның хыяллары һәммәсенеке дә бер: тизрәк әти-әниле, гаиләле булу.

– Без игелекле кешеләрнең ярдәмен гел тоеп торабыз. Барлык шәфкатьле йөрәклеләрне безгә бу проектны гамәлгә ашырырга һәм балаларыбызны бәхетле итәргә чакырам, – диде директор.

Әйе, проект та «Бергә булдырабыз» дип атала ич.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

«Икеле капчыклары» түгел!

Урта һөнәри уку йортларына ничектер кимсетеп карыйлар кебек. Янәсе, көллият югары белемне алыштыра алмый. Шуңа да ата-аналар киләчәктә баласының бу һөнәр буенча эшләргә нияте булмавын белсә дә, вузда укытып чыгарырга тырыша.

Алисә САБИРОВА

Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры урынбасары Лариса Сулима сүзләренчә, урта һөнәри белем бирү йортлары бүген кайбер вузлар белән көндәшлеккә керә ала. Аныңча, көллият һәм техникумнарны «икенче сорт» итеп карау зур хата.

– Инде ике дистә ел урта һөнәри белем алучыларга «өчле капчыгы», «мәктәптә дә юньләп укый алмаган», «пешмәгән» кебегрәк сүзләрне ишетергә туры килә. Мин, мәгариф тармагында озак еллар эшләгән кеше буларак, кулымны күкрәгемә куеп әйтә алам: бу алай түгел. Күптән түгел генә республикабызда «WorldSkills» эшче һөнәрләр чемпионаты үтте. Анда катнашучылар арасында бер генә дә «2»легә укучы юк. Зиһенле, актив, үз максатларына ирешә торган балалар. Ләкин аларга һәрвакыт кимсетеп карыйлар. Һөнәри уку йортларына вуз күләгәсеннән чыгарга вакыт. Бөтен кеше дә җитәкче йә сәүдәгәр була алмый. Кул белән эшләүчеләр дә кирәк безгә, – диде Лариса Сулима.

– Хәзер заманасы башка. Уку биналары төзек, матур. Һәркайсы алдынгы технологияләр белән җиһазландырылган. Хәтта кайбер югары уку йортларында да мондый мөмкинлекләр юк, – дип белдерде Казан шәһәре Башкарма комитетының балалар һәм яшьләр эшләре комитеты рәисе Айрат Фәизов.

«Югары уку йортына керә алмаган, хулиган абитуриентлар техникум белән көллияткә агыла» дигән сүз дә дөрес түгел икән. Лариса Сулима белдергәнчә, узган ел мондый уку йортларында белем алучы укучылар тарафыннан бер генә хокук бозу да күзәтелмәгән.

– Хәзерге вакытта һөнәри уку йортларының дәрәҗәсен арттыру буенча саллы эш алып барабыз. Балалар да, ата-аналар да тәпле һөнәрнең карьерага беренче адым икәнен аңларга тиеш. Укуга гына түгел, иҗат дөньясына, студентлар үзидарәсенә дә игътибар зур. Студент тормышы кызыклы да булырга тиеш, – диде Лариса Сулима.

Шул уңайдан республикада ел дәвамында һөнәри уку йортлары студентлары өчен төрле кызыклы чаралар һәм фестивальләр үтә. Мәсәлән, алдагы елларда студентлар арасында бара торган «Ел студенты» бәйгесендә югары уку йортлары да, урта һөнәри уку йортлары да бер дәрәҗәдә көч сынаша иде. Хәзер урта һөнәри уку йортларының «Ел дәрәҗәсе» дигән үз конкурсы бар. Быел ул 11 февраль көнне узды. Студентлар «Ел интеллекты», «Елның иҗади шәхесе», «Ел волонтеры» кебек 11 номинация буенча көч сынашты. Әлмәт шәһәренең политехника техникумы студенты Айсан Хәбибуллин бәйгенең гран-при иясе булды. Җиңүчеләр «Россия ел студенты» бәйгесендә катнашачак.

Икенче зур вакыйга – «Язгы тамчы» («Весенняя капель») иҗат фестивале. Быел ул XXI тапкыр оештырылачак. Гадәттә ул февраль-апрель айларында була.

– Узган ел фестивальдә 10 мең студент катнашты, быел 15 мең булыр дип көтәбез. Сайлап алу турлары 18 февраль көнне Тәтеш шәһәрендә башланып китәчәк, – дип таныштырды бәйге белән Айрат Фәизов.

Фестивальнең темасы – «Минем Дөньям. Минем Җирем». Әлеге теманы ачу өчен, һәр уку йортына 30 минутлык вакыт бирелә. Биредә алар хореография, вокал, театр осталыгы, оригиналь жанр буенча ярышачак. Быел шулай ук «арт-профи» дигән яңа номинация дә өстәлгән. Биредә студентлар үз һөнәри осталыкларын сәхнәләштерергә тиеш. «Фото күргәзмә» дигән номинациядә яшь фотографлар көч сынашачак.

– Бу фестиваль – 2019 елда Казанда узачак «WorldSkills» чемпионатына да үзенчә әзерлек. Без монда чемпионат ачылышын бизәүче иҗади коллективлар туплаячакбыз, – диде Лариса Сулима.

Һөнәри уку йортлары студентлары эш белән дә сынатмый. Узган ел гына да 11 660 яшьләр студентлар хезмәт отрядында эшләгән.

– Һөнәри уку йортлары Кырым республикасында авыл хуҗалыгы отрядларында, кунакханәләрдә актив эшләде. Бигрәк тә Казан сервис көллияте, Бөгелмә, Буа, Кукмара уку йортлары аерылып торды. Татарстаннан читкә чыгасы килмәгәннәр сәламәтләндерү лагерьларында эшли. Былтыр 35 һөнәри уку йорты студентлары поездда проводник булды. 17 февраль көнне – Россия студентлар хезмәт отрядлары көнендә – иң актив укучыларны бүләкләячәкбез, – диде Татарстанның студентлар хезмәт отрядлары үзәге директоры Ринат Садыйков.

Универсиада авылында урнашкан 4нче шәһәр студентлар сырхауханәсе республиканың 30лап югары уку йортына, 38 урта профессиональ белем бирү учреждениесенә хезмәт күрсәтә. Көндезге бүлектә укучы студентларның бөтенесе дә алар аша уза. Үзәктә кызыклы гына проектлар эшләп килә. Әйтик, «Равный-равному» программасы, «Үзара дус яшьләр клиникасы» хакында озаклап сөйләп булыр иде.

Нәтиҗәле программалар

Соңгысы дүрт «д» принцибына корылган икән («добровольно», «доступно», «доверие», «доброжелательность»).

– Студент аноним рәвештә килеп, табиб белән (психолог, гинеколог, уролог, терапевт) бергә-бер калып, үзенең проблемалары хакында сөйләшә. Әлеге программа аша җиде меңләп студент узды инде. Бу алым кирәкмәгән нәтиҗәләрнең 80 процентка кадәрлесен булдырмый калу яки алардан бөтенләй котылу мөмкинлеген бирә. Нинди генә четерекле проблемалар белән килмиләр студентлар безгә. Белгечләребез моның өчен махсус рәвештә укыдылар, шушы максатта аерым штат, хәтта блок булдырылды, – ди баш табиб Айрат Зиатдинов.

«Равный-равному» программасы да үзенчәлекле. Сигез волонтерлар төркеме төрле югары уку йортларына килеп, тәмәке тартуның зыяны, наркотикларга, алкогольгә бәйлелек хакында студентлар белән сөйләшүләр алып бара. Монысы да хәрәкәттәге проект. Булачак медиклар бу проектта бик теләп катнаша. Иң мөһиме, без моның нәтиҗәсен күрәбез, диләр табиблар.

Турыдан-туры яшьләр белән эшләүче үзәк буларак, әлбәттә, бирәдә IT программалар да актив кулланышта. Әйтик, табиблар белән социаль челтәрләрдәге сайтларда аралашу киң кулланылыш алган. Мөрәҗәгатьләрнең 80 процентка якыны аралашу вакытында ук хәл ителә икән. Монда да махсус куелган психологлар ярдәменә таяна алар. Бер сүз белән әйткәндә, студент яхшы укырга гына түгел, сәламәт тә булырга тиеш.

Расиха ФӘИЗОВА.



Автор фотосы

Тайга кызы

Гадәтем шундый, иртән эшкә килү белән, электрон почтамны ачып, хатларны укыйм һәм «Матбугат.ру» сайтына кереп, ил-көндәге яңалыклар белән танышам. Беркөнне дә «Матбугат»тагы бер язманың баш исеме кызык тоелды. «Элеккеге мәктәп директоры – аучы» дип атала иде ул. Кайсы районның кайсы мәктәбеннән икән, дип кызыксынып ачып карасам, фотосурәттән элеккеге укытучым Сәфинә апа Алиуллова карап тора. Кулында – ау мылтыгы.

Йолдыз ШӘРАПОВА

Авыл мәктәбенә яшь укытучы килү зур яңалык кына түгел, олы шатлык та иде ул чакта. Алабуга пединститутын тәмамлап, берьюлы ике яшь укытучының мәктәбебезгә кайтуы без укучылар өчен чын бәйрәм булды. Узган гасырның 1975 елы иде ул. Алар белән мәктәбебезгә яңа түгәрәкләр, кызыклы чаралар да кайтты. Укытучыларның берсе – Илсөяр, икенчесе Сәфинә Тләшевалар иде, икесе дә рус теле укытучылары, Пермь ягының Барда районыннан. Безнең Яңа Тинчәленең кайда икәнен дә белмичә килгәннәр. Дөресрәге, диплом алгач, кая җибәргәннәр, шунда барганнар. Башта кызларның икесен ике авылга җибәрмәкче булганнар, «Бергә барасыбыз килә!» – дигәч, мәгариф бүлеге мөдире: «Барыгыз алайса Тинчәле басуларында гуляйте!» – дип җибәргән. Илсөяре өч елдан соң туган якларына кайтып китте. Сәфинә апа, балачагы тайга урманының бай табигате арасында узуга карамастан, безнең ялан кырда урнашкан авылыбызны үз итте. Сыңар кулын сугышта калдырып кайтса да, Сабантуй мәйданында гел батыр калган колхозыбыз агрономы Искәндәр абыйның улына кияүгә чыгып, үзебезнең авылныкы булып куйды. Үзе, бу елларны хәтерләп, болай ди:

– Укыласы никахым, туасы балаларым шунда булгангадыр инде, гомерлеккә Яңа Тинчәледә яшәп калдым. Кияүгә чыгасымны белгәч, үзе дә читтән килгән хезмәттәшем Миңнура апа Җамалетдинова: «Еракта калма, туган җирдән читтә яшәүләре кыен булыр», – дип үгетләп тә карады. Яшь чакта кемне дә булса тыңлыйсыңмыни инде ул?! Ярый анысы, үкенеп яшәмәдем, иптәшем дә, каенана-каенатам да бик әйбәт кешеләр булып чыкты. Өч ул үстердек. Яратып эшләдем, яратып яшәдем.

14 ел буе Ниязый Фәизов исемен йөрткән данлы мәктәп дилбегәсен тартты директор. 16 ел уку-укыту эшләре буенча мөдир дә булды. Бик итагатьле, гадел, тавышын да күтәрми торган, ләкин белемне күңелләргә уеп сала белә торган укытучы булып хәтеребездә калды ул Сәфинә апа. Шуңа күрә дә аның кулында ау мылтыгы күргәч, үз күзләремә үзем ышанмый тордым. Ләкин соңрак аны әйбәт белгән кеше буларак, күңелен аңладым. Табигать баласы булып, тайгада үскән кызның җаны монда да киңлек, иркенлек, җәнлек-җанварлар белән аралашу тели, туган ягын сагынганда ул шулай елга буйларында, басу-кырларда йөреп, сагышларын тарата. Аучылыкка энесе Сөләйман өйрәтә аны: мылтыкны корырга, сүтеп майларга, төз атарга, җәнлек-җанварларның холкын аңларга. Этләрен ияртеп, апалы-энеле аз иңләмиләр алар туган якларындагы тайга урманнарын. Ә тайгада көндез дә караңгы – кояш нурлары калын агачлар аша сүрән төшә. Аучыларны еш кына кәтелмәгән куркыныч хәлләр дә сагалый. Хәтта бүре белән дә очрашырга туры килә. Ләкин җәй көне бүреләрнең тамагы тук булганда, алар, гадәттә, кешегә ташланмыйлар. Бу юлы да, бәхеткә, бүре – үз сукмагыннан, аучылар үз юлларыннан китә. Урман ешлыгында аю белән дә очрашырга туры килә, аюның да эше каты: кура җиләге белән сыйланып торган чагы була, исе китми.

Яңа Тинчәледә тайга кызының аучылык шөгыле хобби булып кына калган инде хәзер, чөнки бездә киек җәнлекләр белән тулган урман юк. Куян артыннан куса гына инде. Анысы булгалый, ләкин беркайчан да максаты аларны атып үтерү түгел. Мылтыкны да кыяфәте килсен һәм кыргый этләрдән сакланыр өчен генә ала хәзер Сәфинә Алиуллова. Бишенче сыйныфта укучы оныгы Гөлназны да, табигатьне яратырга, кош-кортларга игътибарлы булырга өйрәтер өчен, үзе белән ияртә. Урманнары-күлләре белән мактана алмаса да, туган авылыбызның табигате үзенчәлекле – Тинчәледә байбаклар яши. Алар Татарстанның ике генә районында: бездә һәм Азнакайда. Буа суында тагын кондызларыбыз бар. Менә шуларны күзәтергә ярата Сәфинә апа. Аларның аз калуына җаны әрни, кешеләр аларны мае файдалы булган өчен юк итәләр икән.

Лаеклы ялга чыгып, мәчет каршындагы мәдрәсәгә дин гыйлеме нигезләрен өйрәнергә йөри башлагач, аучылыкның хәләл икәнен дә белә. Аллаһы Тәгалә әйткән: «Без, сез туклансын өчен, киек хайваннар һәм кошлар булдырдык. Алар сезнең тәрбияне таләп итми. Тик хәләл булсын өчен, ау этләрегезне һәм укларыгызны «Бисмилләһи Аллаһу әкбәр!» дип җибәрегез» (Коръән-Кәрим, «Маидә» сүрәсе. 4нче аять; «Хиҗер» сүрәсе, 20нче аять). Сәфинә апаның тагын бер яраткан шөгыле – гөмбәгә йөрү. Юлында очраган дару үләннәрен дә җыеп алып кайтып киптерә, аннары гаиләсенә кыш буе үлән чәе эчертә. Кергән күршеләрен дә үзе тозлаган гөмбә белән сыйлый.

– Хәзер Тинчәле каенлыкларында нинди генә гөмбә юк. Аны җыюның рәхәтлеген берни белән дә чагыштырырлык түгел, нервларны тәләсә нинди дарууга караганда да яхшырак тынычландыра. Аннары кыш буе тәмле хәләл ризык белән сыйланасың һәм фотоларын карап юанасың, – ди Сәфинә апа.

Төрле конкурс-ярышларда катнашырга да ярата ул. Әнә фотосын районның «Байрак» газетасына конкурска җибәрүе дә яраган. Лаеклы ялдагы укытучы – 63 яшьлек тайга кызы Сәфинә Алиуллова җиңүче дип табылган.

ГОРЕФ-ГАДӘТ

Ярәшү йоласын кайтаралар

Казанның ЗАГС идарәсе Гашыйклар көненә рус һәм татар халыкларына хас булган ярәшү йоласын уздыру традициясен яңартырга уйлый, дип хәбәр итә Казан шәһәре мэриясенең рәсми сайты.

Вәгъдәләшү-ярәшү йоласы русларда һәм татарларда элек-электән килгән, шул көннән башлап яшьләр кияү һәм килен булып саналган, туйга әзерләнә башлаганнар. Вакытлар узу белән, бу гадәт үзгәргән, әмма үз кыйммәтен югалтмаган. Әлеге вакыйгага тантаналы һәм матур төсмер биреп була. Тантана үз эченә сөйгәненең йөзек бирү, кияү һәм кәләшнең романтик биюен һәм башкаларны алырга мөмкин. Тантанада шулай ук әти-әниләр, туган-тумачалар һәм дуслар катнаша ала. Гаилә үзәгендә ярәшү йоласын бүген – Гашыйклар көнендә уздыралар.

ПОЧТАДАН

Имам йортын бергәләп төзедек

Питрәч районының Шәле авылы – Татарстандагы иң зур авылларның берсе. Бирегә ике мәчет, бер мәдрәсә эшләп килә. Авыл халкының олысы да, кечесе дә дингә тартыла, мәчетләребезнең буш торганы юк, шөкер.

«Заһир» мәхәлләсе мәчетендә менә өченче ел инде Тимур хәзрәт Латыйпов имам булып тора. Имам эше – җаваплы эш. Мөселман өммәтен, халыкны тәрбияләү, өйрәтү – хәзрәтнең төп вазифаларынның берсе. Тимур хәзрәт аеруча яшьләргә һәм балаларга дини тәрбия бирүгә, әби-бабайларыбызның эшен дәвам итүгә өстенлек бирә.

– Яшьләрне бүгенге дөнья шаукымыннан, ялгыш юлга кереп китүдән аралап калу, ислам диненең асылын аңлату – безнең уртак бурычыбыз, – ди ул.

Һәр эштә дә тәгәллекне яратучы Тимур хәзрәткә өметләре зур Шәле авылында. Аның турында авыл халкы да:

– Хәзрәтебез безнең бик таләпчән, чисталыкны ярата, кешеләргә мөлаем караштa. Эшне вакытында башкарганны хуплый. Эшләребез дә шулай уңышлы барыр дип уйлыйбыз, – ди.

Тимур хәзрәт имам вазифасына алынгач, кыска гына вакытта бирегә күп эшләр башкарылды. Мәчетнең идәне җылытылды, тәһарәтханәләр эшләнелде, түшәм төзекләндерелде, ишекләргә аркалар куелды, коридорлар яңартылды. Бөтен идәнгә келәм җәелде. Мәчетнең ишегалды төзекләндерелде, бирегә хәтта фонтаннарга кадәр бар. Иң мөһиме – мәчеткә килә торган юллар яхшы.

Шушы көннәрдә тагын бер мөһим вакыйга булды – мәчеттә рухи ядкярләр музее үз эшчәнлеген башлап җибәрде. Бирегә әби-бабаларыбыздан калган дини әдәбият урнаштырылачак. Авылдашларның тырышлыгы белән, беренче экспонатлар килә башлады инде. Бу эш тә хәзрәт тырышлыгы белән башкарыла.

Моңа кадәр хәзрәтнең яшәргә торагы юк иде. Мәчет картлары, авыл халкы бер фикергә килеп, авылда имам йорты салырга булдылар һәм кыска вакыт эчендә йорт төзелеп тә куйды. Әлбәттә, хәзер язуы гына җиңел. Әлеге йортны төзүдә барлык авыл халкы үз өлешен кертте. Шулай ук Татарстан Дәүләт Советы депутаты, «Газпром Трансгаз Казан» җәмгыяте генераль директоры Рәфкать Кантюков, «Приволжскгаз» башлыгы Ильяс Галимов, Россия мөфтиләр советы рәисе – Шәле авылында туып-үскән Равил Гайнетдин, Питрәч РЭГС башлыгы Рамил Зәйнуллин, «РАЦИН» предприятиесе генераль директоры Әсхәт Шәрапов та имам йорты төзелешенә ярдәм итте. Ә Шәле авылында яшәүче Фатыйма апа Таҗиевага аерым рәхмәт – ул барлык эшне дә башлап йөрүче булды.

Шулай итеп, уртак көч белән зур эш башкарды Шәле халкы. Алга таба да бердәм булып, ислам диненең асылын аңлап, тату матур гомер кичерергә язсын иде. Мәчетләребезнең ишекләре ачык булсын. Гыйбадәтләребезне Аллаһы Тәгалә кабул итсен, көтелмәгән җирдән куәтләр бирсен, матур тормышыбыз дәвамын күрергә насыйп булсын иде дигән теләктә калам.

Гүзәл САФИНА,
газета укучы.

Антифриз җимеш суы түгел

Татарстанда атна саен 14-17 кеше алкоголь һәм спирт катнашмалы сыекчалардан агуланып, медицина учреждениеләренә мөрәҗәгать итә.

VK.com

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина Sntat.ru электрон газетасына биргән әңгәмәсендә телгә алынганча, республикада узган ел 776 кеше агуланган, шуның 267се үлгән.

Иркутск шәһәрендә узган елның 23 декабрендә «Боярышник»тан массакүләм агуланудан соң Россиянең Баш санитар табибы махсус карар кабул итте. Составының 25 проценттан күбрәк өлешен спирт тәшкил иткән, азык-төлек исемлегенә карамаган, продукцияне сатуга вакытлы чикләү кертте. Быелның 24 гыйнварында әлеге карар янә 60 көнгә озынайтылды. Таләпне үтәмәүнең 12 очрагы ачыкланган, аларга административ чара күрелгән.

– Агуланучыларның 23 проценты – азык-төлек саналмаган спиртны кулланучылар. Мондый спиртлар автомобиль тәрәзәсен юдыручы сыеклыкларга, антифризга, техник спиртларга кушыла. Кызганыч, кайберәүләр шушы сыекчаларны эчәләр. Метил спирты эчкән очракларның 90 проценты үлем белән тәмамлана, – ди Любовь Авдонина.

Татарстандагы сәүдә оешмалары Россиянең Баш санитар табибы һәм Роспотребнадзорның республика буенча идарәсе күрсәтмәләренә җаваплы караган. Республика буенча 1900 сәүдә ноктасында таләпне үтәмәүнең 12 очрагы гына ачыкланган.

– Россиянең башка төбәкләре белән чагыштырганда, Татарстанда агулану очраклары бермә-бер азрак. 2006 елдан бирле спирт катнашмалы сыекчалар кулланып агуланулар 4,6 мәртәбәгә, шул сәбәптәге үлем 1,3 мәртәбәгә кимеде. Республикада профилактикага һәм сәүдә челтәрендә сыйфатсыз продукция сатуны чикләүгә нык игътибар бирелә, – ди Любовь Ананева.

Спирт катнашмалы сыекчаларны яшертен сатучыларны фаш итүдә җәмәгатьчелекнең дә активлыгы зарур. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсенең «кайнар элемтә» телефоны: **(843) 236-94-11.**

БӘЙГЕ

16-17 февральдә Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтында «Әлмәндәр оныклары» фестивале узачак. Ул Татарстан Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерү фонды, Мәдәният министрлыгы, Фән һәм мәгариф министрлыгы, Камал, Тинчурин, Кариев, Качалов театрлары ярдәме белән оештырыла. Фестиваль СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров истәлегенә багышлана.

«Әлмәндәр онываклары»

– Киләсе елда Шәүкәт Биктимеровның тууына 90 ел тула. Ә яшьләр аны беләләрме? Театр өлкәсендә нинди ачышлар бар? Фестивальнең төп максаты – милли драматургияне пропагандалау, балаларны милли театрга тарту, яшь тамашачыда зәвык тәрбияләү, сәләтле балаларны ачу. Узган ел анда 66 коллектив катнашты. Балаларга алты-җиде яшьтә үзләрен артист итеп тою – зур бәхет, – дип сөйли институт профессоры Рафаэль Вәлиев.

Педагог Илсөяр Шиһапова әйтүенчә, фестивальне оештыру идеясе белән театр факультеты деканы Руфинә Таҗетдинова чыккан. Бередә сан түгел, эчтәлек мөһим. Балаларның талантлыларын күреп, киләчәктә аларны институтка укырга чакырырга мөмкин булачак. Үзешчән сәнгать ул – профессиональ сәнгатьнең нигезе.

– Безнең хөкүмәтебезнең театрларга карата игътибары арта бара. Яшьләрне театрга тарту үзе мактауга лаек. Шәүкәт Биктимеровның иҗаты онытылмасын иде, – ди Мәдәният министрлыгы белгече Аида Мозаффарова.

«Мәйдан» каналы режиссеры Эдуард Үтәгәнов – фестивальдә жюри әгъзасы.

– Узган ел мин «Сәнгатьле сөйләм» төрендә балаларга бәя бирдем. Алар миндә матур тәэсирләр калдырды, чөнки хәзерге балалар әдәбиятка, шигърияткә бик үк тартылмый. Безнең максат – балаларда сәнгатьле сөйләмгә мәхәббәт уяту, – ди ул.

Фестивальнең жюри рәисе – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Илдар Хәйруллин.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА.

Казан шәһәре Башкарма комитеты аппараты, шәһәр Башкарма комитетының контроль һәм коррупциягә каршы эш идарәсе хезмәткәре

Сергей Владимирович ГЕРАСИМОВның

вакытсыз вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең туганнарының, якыннарының авыр югалту кайгысын уртаклаша.

Җиңүченең китабы чыгачак

Үзегезне әдәби бәйгедә сынап карыйсыгыз, шул ук вакытта китап чыгару уе белән яшисез икән, сезгә барысы да кулай килеп тора дияргә була. Чөнки «Татмедиа» республика агентлыгы, «Татарстан» журналы белән берлектә, «Татарстан» журналы премиясенә конкурс игълан итә.

Бәйге татар әдәбиятына зур өлеш кертергә сәләтле әсәрләр һәм талантлы авторлар эзләп табу максатын куя үз алдына. Конкурста моңа кадәр беркайда да басылып чыкмаган роман, повесть, хикәяләр циклы кульязмасы катнаша ала. Төп шарт: әсәрләр Татарстан турында булырга яки автор Татарстанда яшәргә тиеш. Кульязмалар рус һәм татар телләрендә кабул ителә. Жюри тарафыннан сайланып алынган әсәрләр ел дәвамында «Татарстан» журналы битләрендә һәм журнал сайтында (protatarstan.ru) бирелеп барылачак.

Быелның декабрь аенда татар һәм рус телендә берәр җиңүче әсәр сайланачак һәм алар китап булып дөнья күрәчәк. Китап чыгару елдан-ел кыйммәтләнгән, авырлашкан заманда, авторлар өчен моннан да зур бүләк була алмый.

Конкурста катнашучыларга таләпләр дә зур. Кульязма, һичшиксез, электрон версиядә булырга тиеш. Автор турында тулы мәгълүмат, әсәрләр исемлеге булу да мәҗбүри.

Конкурсны үткәрү вакыты 2017 елның 19 гыйнварыннан 2017 елның 15 декабренә кадәр.

Кульязмаларны **tatarstan@tatmedia.com** адресына «Конкурска» дип җибәрергә кирәк.

«Созвездие – Йолдызлык»ны хуплыйлар

Яшьләрнең «Созвездие – Йолдызлык» телевизион республика фестивален Россия Федерациясенең ЮНЕСКО эшләре буенча комиссиясе үз канаты астына алды. Бу хакта комиссиянең җаваплы сәркатибе Григорий Орджоникидзе фестиваль җитәкчеләренә хәбәр итте.

yold.ru

– Без 2017 елда фестиваль белән хезмәттәшлекне дәвам итүебезгә шатбыз. Татарстанның төп балалар фестивале чын мәгънәсендә республиканың мәдәни брендына әйләнде. Илебез өчен ул уникаль яшьләр проекты булып исәпләнә һәм тулысынча ЮНЕСКОның максатларына һәм бурычларына туры килә, – диде ул.

Григорий Орджоникидзе әйтүенчә, ЮНЕСКО комиссиясе әгъзалары суперфиналда һәм гала-концертта катнашачак.

Быелгы фестивальнең зона турлары 1 марттан 30ына кадәр үтәчәк.

Фестивальнең суперфиналы – 10-14 апрельдә, беренче гала-концерт 15ендә – «УНИКС»та, икенчесе 22 апрельдә «Пирамида»да узачак.

Шул да булдымы исем?!

Сенатор Валентина Петренко балаларга аббревиатура, сан, вазифа атамалары кергән исемнәрне куюга каршы чыккан. Аны Дәүләт Думасының дәүләт төзелеше һәм законнар чыгару комитеты да хуплаган. Петренко тәкъдиме буенча, хәзер балага Ренат («революция», «фән», «хезмәт» сүзләреннән кушылып ясалган исем), Владлен (Владимир Ленин) кебек исемнәрне кушу закон тарафыннан тыелган булырга мөмкин.

lovelus.com

Бу исемлеккә шулай ук Дамир («Да здравствует мировая революция», «Да здравствует мир» яки «Даешь мировую революцию»), Ким («Коммунистический интернационал молодежи»), Ленар («Ленин армиясе»), Ленур («Ленин учредил революцию»), Рамил («Рабочая милиция»), Радик («Радий»), Эльмира («Электрификация мира»), Эмиль («Энгельс, Ленин, Маркс»), Энгель («Энгельс») исемнәре дә кергән.

Ләкин әлеге исемнәргә аббревиатура итеп кенә карамаучылар да җитәрлек. Мәсәлән, Ренат латин теленнән «Renatus» – «яңадан туган» дигәнне аңлата. Совет замынында гына ул Идел буе татарлары һәм башкортлары арасында революцион төсмер алган. Әлеге исем Италия, Испания, Португалия, Польшада да киң таралган. Татарстанда популяр булган Ленар исеме дә ике төрле мәгънәгә ия. Башта ук аны гарәп теленнән «Аллаһ нуры» дип тәрҗемә иткәннәр. Бу нечкәлекләрне күздә тотып, кайбер депутатлар көндәлек тормышка инде кереп киткән исемнәрне үзгәртүгә каршы чыккан.

Сүз уңаеннан. 2002 елның 26 июнендә Мәскәүдә туган бер малайга әти-әнисе БОЧрРф 260602 дигән исем куштырган. Бу «Биологический объект человека рода Ворониных—Фроловых, родившийся 26 июня 2002 года» дигәнне аңлата. Хәзер малай инде 10 ел документларсыз яши, чөнки суд әлеге исемне теркәргә теләмәгән Мәскәү ЗАГСы карарын дөрес дип тапкан.

Ә сез ничек уйлыйсыз?

Рамил ШӘРӘПОВ, шоу-мен:

– Ул сенаторга әйтегез: үз исемен тыйсын, кешенекенә тимәсен! Миңа бу исемне әни кушкан. Рамил «тылсымчы» дигәнне аңлата. Минем бит ике исем. Паспорт буенча Рамил булсам, мулла кушкан исемем — Сәетҗан. Әни мөселманча булсын, тормышы җиңел, күңеле тыныч булсын дип шулай эшләгән, күрәсең. Кешегә нинди исем кушарга икәнен өйрәтеп утыру, минемчә, дөрес әйбер түгел ул. Депутатларның башка эше беткәнме?! Халык тормышын җиңеләйтә торган законнар уйлап тапсыннар. Пенсионерлар, мөмкинлекләре чикле кешеләр, ятимнәр бар – аларга өстәмә ярдәм ясау чыганаклары табарга тырышсыннар.

Ким МИҢНУЛЛИН, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры:

– Әлбәттә, исем кушуның нинди дә булса тәртибе булырга тиеш. Без дәүләттә яшибез икән, үзебезне акыллы кеше итеп йөртәбез икән, башыбызга нәрсә килә, шуны эшли алмыйбыз. Гомум кабул ителгән нормалар, принциплар бар. Закон кабул ителә калса, фән белгечләре, журналистлар халыкка исемнең дәрәҗәсен, мөһимлеген дә җиткерергә тиеш.

Шунысы бар, безнең халык илдә барган сәясәткә, идеологиягә сизгер. Бу исемнәрдә дә чагыла. Минем исем дә замана сулышы. Әни, 30нчы елларда Уфа шәһәренең балалар йортында тәрбияләнгән кыз буларак, «кызыл тәрбия» алган. Ул партия дип янып йөргән. Тикмәгә генә, 34 яшендә өч бала белән тол калгач та, коммунистлар партиясенә кермәгәндер инде. Ул чор яшьләренең рухы башка иде. Шуңа да минем яшьтәшләр арасында бу исем киң таралган. Алар – идеологик юнәлеш, бөтен дөньяда гаделлек булдыру юнәлешендә үскән буын. Халыкара яшьләр оешмасының значоклары да бар әле минем.

Эмиль ТАЛИПОВ, Камал театры артисты:

– Исем – ата-ананың балага биргән хәер-фатихасы. Исеме кешене гомер буе яктылыкка, нурга өндәргә тиеш. Миңа бу исемне әти куштырган. Заманасы шундый булгандыр инде, чөнки апамның исеме дә Эльфа. Ә Эмиль «үз максатына ирешә торган, көрәшүче кеше» дигән мәгънәгә ия. Үз исемемне беркайчан да революция белән бәйләгәнем булмады. Мин инде аңа күнеккән, исем кушканда мулла да каршы килмәгән. Үзем дә һәрвакыт ярышып яшим. Яхшырак булырга, беренчелеккә чыгарга омтылам. Бу мәсьәләне закон рәвешендә чыгарырга кирәкме-юкмы икәнен тәгаен әйтә алмыйм, ләкин моны ниндидер тәртипкә салырга кирәктер. Юкса хәзер балага эт, мәче кушаматлары, саннар бирә башладылар. Бу бит мәгънәсезлек. Бала үзенә-үзе исем сайлый алмый. Шуңа да ата-аналар бу эшкә җаваплы карасыннар иде.

25 февраль көнне «Болгар радиосы» Милли музыкаль премиясенең 25 җиңүчесе билгеле булачак. Оештыручылар номинантлар исемлеген әлегә сер итеп саклый. Араларында яшь җырчы Ришат Төхвәтуллин белән Татарстанның атказанган артисты Гөлдания Хәйруллина булуы гына билгеле.

«Алтын йолдыз»лар көтә

Инде дүртенче тапкыр оештырылган премия быел да татар эстрадасында иң-иңнәрне барлау максатына тугры кала.

– Премия башка артистларга да тырышып эшләргә этәргеч булып торачак. Ә төп үзенчәлегебез – авторларга игътибар. Җыр язучы авторлар башкаручылар белән бер сәхнәдә басып торачак, – диде «Болгар радиосы» баш мөхәррире-продюсеры, IV «Болгар радиосы» Милли музыкаль премиясе тапшыру тантанасы алып баручысы Илфар Кәримов.

Быел тантананы өч пар алып бара. Алар барысы да – «Болгар радиосы» ди-джейлары. Һәр җырчыга тапшырыла торган премиянең сыны да исемле: җиңүчеләргә «Алтын йолдыз» тапшырачаклар.

– Әлеге премия – татар мәдәниятен үстерү чарасы. Быел «Узган гомер җәл булмый» дигән җырым номинант булды. Көн саен аның өчен сигез-ун мең кеше тавыш бирде, – диде җырчы Гөлдания Хәйруллина.

Ришат Төхвәтуллин исә инде өченче тапкыр җиңүче.

– Минем өчен җаваплы, ел дәвамында көтеп алынган премия бу. Җырчы иҗатына бары тамашачы гына дөрес бәя бирә ала. Бу исә бәйгедә җиңгән артист нәчар җырчы була алмый дигән сүз. Яшьләр өчен дә аның әһәмияте зур, – диде ул.

Исегезгә төшерәбез, премиянең номинантлары маркетинг тикшеренүләре, җюри экспертлары фикере һәм музыка индустриясе белгечләре тарафыннан «Болгар радиосы»ның хит-парадында халык тавыш бирү нәтиҗәсендә сайлап алына.

– Җырларны сайлап алганда, халык фикеренә дә колак салабыз, ел дәвамында эшләгән үзебезнең сәнгать советы фикерен дә карыйбыз. Шунысы кызык, халык белән сәнгать советы фикере әллә ни аерылмый. Димәк, тыңлаучы да сыйфатлы җырга омтыла, – диде Илфар Кәримов.

Алисә САБИРОВА.

Хоккей легендалары киләчәк


razan.kp.ru

15 февраль көнне Казанда дөньякүләм хоккей легендалары арасында дусларча матч узачак, дип хәбәр итә Казан мэриясе порталы. Спорт сарае бозына Татарстанның җыелма командасы һәм «Филадельфия Флайерз» профессиональ клубы ветераннары чыгачак. Матчта Алексей Чупин, Дмитрий Балмин, Кирилл Голубев, Евгений Захаров, Скотт Макферсон, Эл Секорд, Боб Капентер кебек йолдызлар катнашыр дип көтелә. Уенны карау бушлай. Визит кысаларында легендар спортчылар Казанның күренекле урыннары белән танышачак. Матчтан соң икенче көнне алар Казан һәм Татарстанның яшь хоккейчыларына мастер-класс уздырачак.

Шәһри Казан

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ – БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – РАСИХА ГАБДЕЛБӘР кызы ИСМӘГЫЙЛОВА.
© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.
РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1545. Гомуми тираж – 5719.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 676. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77– 50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы